# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“18” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 15 ноябрендә “Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаиләсе әгъзаларынан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме

1) Югары Сәрдә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар сатып алу);
3) Югары Сәрдә авыллы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту агач һәм куакларны кисү, чистарту; (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) Алмяш, Тургай, Яшеллек урамнары буенча Югары Сәрдә авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 134 (йөз утыз дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 91(туксан бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 91(туксан бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип таныргa.
2. “2024 елда Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк

гражданнардан, 1 нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаиләсе әгъзаларынан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Югары Сәрдә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) Урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар сатып алу);

3) Югары Сәрдә авыллы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту агач һәм куакларны кисү, чистарту; (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Алмяш, Тургай, Яшеллек урамнары буенча Югары Сәрдә авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.